УДК 94 (470,41)
EDN XPMSPN

# Каюм Насыйри кульъязмаларының гыйльми кыйммәте хакында Г. Гобәйдуллин (К. Насыйриның тууына 200 ел тулу уңаеннан)

***Л. Ш. Гарипова, Л. Р. Надыршина,***

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Казан шәһ., Татарстан Республикасы, Россия Федерациясе*

# G. Gubaidullin on the scientific value of Kayum Nasyiri's manuscripts (on the 200th anniversary of K. Nasyiri's birth)

***L. Sh. Garipova, L. R. Nadyrshina,***

*G. Ibragimov Institute of Language, Literature and Art, the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan, Kazan, the Republic of Tatarstan, the Russian Federation*

**Аннотация**

В нынешнем году отмечается 200-летие со дня рождения известного татарского просветителя Каюма Насыри, оставившего после себя огромное научное наследие. Труды Каюма Насыри охватывают многие сферы татарской гуманитарной науки – языкознание, историю, этнографию, а самого мыслителя справедливо называют основоположником современного литературного языка. Значительную часть его научных изысканий составляют и книги по естествознанию, также под руководством К. Насыри издавался ежегодный календарь («Казан календаре»), содержащий научно-популярный и литературный материал. Вниманию читателей предлагается статья Газиза Губайдуллина «О научной ценности рукописей Каюма Насыри», где дается аналитический обзор рукописных трудов татарского просветителя по истории татарского народа, сохранившихся в фондах Казанского университета. В частности, высокой оценки удостаивается исследование К. Насыри по археологии, которое, по мнению Г. Губайдуллина, является первым научным трудом по изучению истории региона. Особо выделяется вклад К. Насыри в исследование татарских эпиграфических памятников и истории древнего Булгара, отмечается значимость его трудов в создании социального портрета татарского духовенства XVI-XVII вв. и др.

**Abstract**

This year marks the 200th anniversary of the birth of the famous Tatar educator Kayum Nasyiri, who left behind a huge scientific legacy. Kayum Nasyiri's works cover many areas of Tatar humanities – linguistics, history, ethnography – and the thinker himself is rightly called the founder of the modern literary language. A significant part of his scientific research includes the books on natural science. Under the guidance of K. Nasyiri, an annual calendar ("Kazan Calendar") was also published, containing popular science and literary material. Readers are invited to read Gaziz Gubaidullin's article "On the Scientific

Value of Kayum Nasyri's Manuscripts", which provides an analytical overview of the Tatar educator's manuscripts on the history of the Tatar people, preserved in the archives of Kazan University. In particular, K. Nasyiri's research on archaeology is highly regarded, which, according to G. Gubaidullin, is the first scientific work on the study of the region's history. K. Nasyiri's contribution to the study of the Tatar epigraphic monuments and the history of ancient Bulgar stands out in particular, and the significance of his works in creating a social portrait of the Tatar clergy of the XVIth-XVIIth centuries, among other things, is noted.

**Ключевые слова**
Каюм Насыри, Газиз Губайдуллин, биография, научное наследие, история татар, Лука Канашевич, Пугачев, татарская эпиграфика.

**Keywords**
Kayum Nasyiri, Gaziz Gubaidullin, biography, scientific heritage, history of the Tatars, Luka Kanashevich, Pugachev, the Tatar epigraphy.

Быел татар җәмәгатьчелеге күренекле татар мәгърифәтчесе Каюм Насыйри тууына 200 ел тулуны билгеләп үтә. Чын мәгънәсендә энциклопедик гыйлемгә ия булган бу шәхеснең тел һәм әдәбият, археология һәм тарих, фольклор һәм этнография, гомумән, фәннең төрле тармакларына караган хезмәтләре татар фәне тарихында тирән эз калдырган. Ул татар балаларына рус теле укыткан мөгаллим, Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыятенең хокукый әгъзасы, күпсанлы дәреслекләр һәм фәнни-популяр басмалар, татар теленең беренче аңлатмалы сүзлеге (ике томлык «Ләһҗәи татар», 1895-1896), энциклопедик характердагы «Фәвакиһел-җөләса фил-әдәбият» (1884) хезмәте авторы, беренче татар календарьларын чыгаручы буларак әдәбият һәм фәнне популярлаштыру юнәлешендә зур хезмәт куя; беренчеләрдән булып татар әдәби телен нигезләү мәсьәләсен күтәреп чыга, «әдәби телнең халыкчан нигездә булырга тиешлеген, башка телләр кебек үк, татар теленең дә фән теле буларак яшәргә тиеш икәнлеген раслый, саф татар телендә язылган хезмәтләре аша аның аны гамәли яктан куллану чикләрен киңәйтә»[1], гомумән, «татарлардан беренче буларак бердәм татар этносы турындагы идеяне нигезли»[2].

Каюм Насыйри хезмәтләре һәрвакыт ныклы фәнни нигезгә утыртылган булуы, яңа мәгълүматларга байлыгы белән игътибарны җәлеп итә. Газиз Гобәйдуллинның укучы хөкеменә тәкъдим ителгән бу мәкаләсендә дә сүз шул хакта бара[3]. Мәкаләдә күзәтү-анализ объекты буларак, күренекле мәгърифәтченең Казан университеты китапханәсендә сакланган дүрт кулъязма җыентыгы[4] – татар тарихының төрле сәхифләрен ачкан ядкәрләре алынган һәм аларның фәнни кыйммәте күрсәтелгән.

Язмада билгеләнеп үтелгәнчә, археология материаллары тупланган кулъязма – арада иң мөһиме, фәнни яктан иң кыйммәтлесе. Аерым алганда, мәкалә авторы бу хезмәттә татар каберташларын өйрәнү өчен әһәмиятле мәгълүматлар урын алуын күрсәтә. Болгар чоры эпиграфик истәлекләре фәндә шактый яктыртылса да, Казан ханлыгы чорына кагылышлы ядкәрләр К. Насыйрига кадәр тикшерүчеләр игътибарыннан читтә калган була. Татарның XVI-XVII гасырга кагылышлы иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни тарихын саклаган шушы каберташлар

энциклопедист мәгърифәтче тарафыннан беренче кат укыла, аерым берләренең, схематик булса да, рәсеме алына. Г. Гобәйдуллин тарафыннан китапның Болгар тарихы һәм XVII-XVIII йөз татар руханилар катлавына караган, шулай ук татар теленә госманлы теле тәэсиренең алшартларын ачыклау буенча кыйммәтле мәгълүматлар чыганагы булуы да ассызыклана, К. Насыйри язып алганнарның моңа кадәр фәнни әйләнешкә кертелмәгән өр-яңа материал булуы раслана. Гомумән, калган өч кулъязма да – Аксак Каратун һәм Пугачев хакындагы хезмәт, Казан тарихы буенча халык арасында йөргән риваятьләргә таянып язылган материаллар, имамнар турындагы язма – болар барысы да Г. Гобәйдуллин тарафыннан югары бәяләнә, аерым бер очракларда төгәлләштерү соралса да, тулаем алганда моңарчы тикшерүчеләр тарафыннан читтә калган фактларны туплаган мәнбәгъ-чыганак буларак тәкъдим ителә.

Мәкалә авторы мәгърифәтче галимнең татар тарихы буенча материаллар җыюда төгәллеген, эзләнүчәнлеген билгели. Чыганакларга тәнкыйди күзлектән карап, халыктан җыйган һәм башка тарихчылардан алган мәгълүматларны җентекләп тикшергәч һәм әдәби эшкәрткәч кенә үзенең хезмәтләренә урнаштыруын ассызыклый. К. Насыри, язмада билгеләп үтелгәнчә, һәрвакыт чыганакны күрсәтеп бара, миф белән тарихи фактны төгәл аерып, беренчеләрен үз хезмәтләренә фәкать этнографик материал буларак кына кертә.

Рәсми галимнәрдән аермалы буларак, К. Насыйри бу эшне бары тик шәхси фидакарьлеге хисабына гына башкара, мәгълүматны «бер җәмгыятьнең субсидиесе, командировкасы, мандаты белән җыймый»[5], җәй көннәрендә үзенең дусты Габделкави мулла белән авылдан-авылга йөреп, халыктан сорашып туплый. Г. Гобәйдуллин югары бәя биргән дүрт кулъязма – зур тырышлык белән бөртекләп җыелган кыйммәтле тарихи ядкәрләр.

Гарәп графикасыннан гамәлдәге алфавитка беренче кат күчерелеп тәкъдим ителгән бу мәкалә олуг татар мәгърифәтчесенең татар тарихына караган фәнни мирасын барлау юлында бер адым булыр, аның шәхес һәм галим буларак портретын төгәлләштерүгә хезмәт итәр. Шулай ук күренекле язучы, тәнкыйтьче, тарихчы, җәмәгать эшлеклесе Газиз Салих улы Гобәйдуллинның (1887-1937) киңкырлы эшчәнлегенең бер өлешен укучыга кайтаруга да өлеш кертер.

**ИСКӘРМӘЛӘР:**

1. *Надыршина Л. Р., Гарипова Л. Ш.* Безләр – татармыз... (К. Насыйриның татар әдәби телен нигезләү юнәлешендәге эшчәнлеге турында) // Гасырлар авазы – Эхо веков Echo of centuries. – 2024. – № 4. – Б. 124-133.
2. *Загидуллин И. К.* Каюм Насыйри – первый идеолог и практик татарского нациестроительства // Татароведение в ситуации смены парадигм: теория, методология, практика: материалы IV Международного научно-практического семинара, посвященного 85-летию Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова, 9-10 октября 2024 года. – Казань: Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ, 2024. – С. 37.
3. *Ногман М.* Н. И. Лобачевский исем. Фәнни китапханә кулъязмаларының тасвирламасы. III чыгарылыш. Каюм Насыйри кулъязмалары. – Казан, 1958. – 49 б.
4. Насыйри кулъязмаларының гыйльми кыйммәтләре турында // Каюм Насыйриның моңарчы басылмаган әсәрләре һәм 100 еллык бәйрәм материаллары. – Казан, 1926. – 135 б.
5. Шунда ук.

